Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

07 ноябрь 2019 ел N 39

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Яңа Кәшер авыл җирлеге
Яңа Кәшер авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын
билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 24 нче ноябрендә, 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Яңа Кәшер авылының Гагарин, Мәктәп, Кече мәктәп, Әхмәдиев, Киров, Тукай урамнарында, Совет урамындагы №1-39 йортларда, Тавабилов урамындагы №1-123 йортларда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Яңа Кәшер авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Мәдәният йорты каршында, Гагарин урамы, 35А йорты.

2. 2019 елның 24 нче ноябрендә, 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Яңа Кәшер авылының Тавабилов урамындагы №124-267 йортларда, Совет урамындагы №40-72 йортларда, Җәлил, Куйбышев, 1 Май урамнарында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авылы җирлегенең Яңа Кәшер авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Тавабилов урамы, 198 нче йорт каршысында.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Кәшер авыл җирлегенең Яңа Кәшер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Яңа Кәшер авылы юлларын норматив хәлгә китерү, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Яңа Кәшер авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Яңа Кәшер авылы, Тавабилова урамы, 153 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат

стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә). .

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) кененнән үз көченә керә.

Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гыйниятуллина